УДК 394

***Л.Ш. Гарипова,***
***Ә.К. Булатова,***
***И.И. Ямалтдинов***

# МОРДОВИЯ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТЕМНИКОВ РАЙОНЫ ТАТАР АВЫЛЛАРЫНА СӘФӘР

В статье представлены результаты комплексной научной экспедиции Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, проведенной в 2025 году в татарских населенных пунктах Темниковского района Республики Мордовия. В ходе научной командировки специалистами различного профиля (диалектологом, фольклористом, археографом, эпиграфистом, искусствоведом) были обследованы села Тарханы, Татарское Акашево, Дашкино, Енгуразово, Адаево, Митрялы, Тювеево, Сухой и другие. В статье также освещается современное состояние татарских сел: деятельность вновь построенных и восстановленных мечетей, роль местных активистов и женских общин в сохранении традиций. Авторами зафиксированы образцы фольклора (свадебные обряды, песни, наигрыши на гармони), элементы традиционной архитектуры и декора, а также диалектные особенности речи темниковских татар, относящейся к западному диалекту татарского языка. Особое внимание уделено археографическим находкам.

Исследование фиксирует процесс угасания ряда малых деревень (Енаково, Акашево) и одновременно фиксирует усилия жителей по сохранению культурной идентичности, памяти о предках и традиций. Экспедиционные материалы вносят значительный вклад в воссоздание целостной картины истории и культуры татарского народа на территории современной Мордовии.

**Ключевые слова:** Темниковский район, Республика Мордовия, татарский народ, наследие, материальная культура, духовная культура

The article presents the results of a comprehensive scientific expedition of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, conducted in 2025 in Tatar settlements of the Temnikovsky district of the Republic of Mordovia. During the scientific trip, specialists of various profiles (dialectologist, folklorist, archeographer, epigrapher, art historian) examined the villages of Tarkhany, Tatarskoye Akashevo, Dashkino, Engurazovo, Adaevo, Mitryaly, Tyuveevo, Sukhoi and others. The article also highlights the current state of Tatar villages: the activities of newly built and restored mosques, the role of local activists and women's communities in preserving traditions. The authors recorded folklore samples (wedding ceremonies, songs, harmony plays), elements of traditional architecture and decor, as well as dialectal features of the speech of the Temnik Tatars, referring to the Western dialect of the Tatar language. Special attention is paid to archaeological finds. The study captures the process of extinction of a number of small villages (Altynkovo, Akashevo) and at the same time records the efforts of residents to preserve cultural identity, memory of ancestors and traditions. The expedition materials make a significant contribution to the reconstruction of a ho-

listic picture of the history and culture of the Tatar people in the territory of modern Mordovia.

**Keywords:** Temnikovsky district, Republic of Mordovia, Tatar people, heritage, material culture, spiritual culture

Мордовиянең татар авылларында рухи мирасыбызны туплау һәм өйрәнү үткән гасырның урталарыннан башланып китә. Бу юнәлештәге эзләнүләрнең башында торган күренекле галим Хәмит Ярми (1904–1981) җитәкчелегендәге фольклор экспедициясе барышында бай материал туплана. Хәзерге көндә бу хәзинәләр ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә саклана (42 нче коллекция). Узган гасырның 50–80 нче елларында Институт диалектологлары Мордовия төбәгендә яшәүче татарларның җирле сөйләш үзенчәлекләрен тирәнтен тикшерәләр. Алар туплаган мәгълүматлар «Татар халык сөйләшләре атласы»нда һәм төрле фәнни хезмәтләрдә [2; 3; 5; 6] чагылыш тапкан.

Әлеге мәкаләдә исә Мордовия Республикасының Темников районы татар авылларына 2025 елдагы сәфәребезнең кайбер нәтиҗәләре белән уртаклашабыз.

Экспедициядә берничә юнәлештә эш алып барылды: диалектолог Ә. Булатова – җирле сөйләш үзенчәлекләрен; фольклорчы И. Ямалтдинов – татар халык авыз иҗатын, гореф-гадәтләрне, йолаларны; археограф Л. Гарипова – кульязма һәм басма китапларны; эпиграфист В. Усманов – борынгы ташъязма мирасыбызны; музыка белгече Г. Гыйлемҗанова – халкыбызның музыка һәм сәнгатен, уен коралларын; сәнгать белгече Л. Шкляева йорт-җир төзелешен, төбәк кул осталарының эшләрен барлады. Нәтиҗәдә әлеге төбәктәге татар авыллары төрле яктан һәм бербөтен итеп өйрәнелеп, мәдәни һәм рухи мирасыбызның ерак тамырларына тирәнрәк үтеп керү юлында чираттагы адым ясалды.

Мордовия Республикасында алтмышка якын татар авылы теркәлгән. Хәзерге Мордовия җирләрендә төркиләр бик борынгыдан яшәп киләләр, бигрәк тә XVI–XVII гасырларда татарлар әлеге төбәккә күпләп килеп урнашалар, бу исә Россия империясенең чик сызыкларын сафка бастыру эшчәнлеге белән дә бәйле [2: 143].

Фәнни экспедиция эшчәнлеге Темников районыннан башланды. 27–30 май көннәрендә әлеге райондагы татар авыллары: Тархан, Акаш, Дашка, Яңгураз, Адай, Митрәл, Теви, Сухойда булып, бай материал тупланды, бүгенге көнгә кадәр халык күңелендә сакланып калган мирасыбыз барланып, соңгы еллардагы үзгәрешләргә дә игътибар ителде, яңа үзенчәлекләр теркәлде.

Темников районы Мордовия Республикасының төньяк-көнбатышында урнашкан. Район үзәге – Темников шәһәре, татарлар телендә әлеге шәһәр Төмән дип йөртелә. Районда 1300 гә якын татар яши. Әлеге җирләрдә Акчурин, Бибасаров, Биглов, Дашкин, Дәүләткилдиев, Дивеев, Енгалычев, Еникиев, Кодашев, Колончаков,

Мәмлиев, Сакаев, Тенишев, Терегулов, Яушев кебек татар морзалары нәселләренең утарлары булган [5: 193].

Тархан авылы Аксел елгасы буенда урнашкан. «Пенза губернасы торак пунктлары исемлеге»ндә (1869) Тархан – Краснослободск өязе карамагындагы 63 йортлы авыл буларак күрсәтелә [6]. Авыл кешеләре тарханнар булган, ягъни алар (Темников чик сызыгында) Рус дәүләтенең көньяк-көнчыгыш чиген саклауда хезмәт иткән кешеләргә ярдәм күрсәткән өчен, тархан ярлыклары (грамоталары) буенча салым түләүдән азат ителгәннәр.

Бай тарихлы Тархан авылында безне 40 ел мәктәптә укытучы булып эшләгән Супаева Зәйнәп Хөснетдин кызы (1956 елгы) каршы алды. Ул безгә авыл, мәчет тарихы хакында сөйләде, борынгыдан килгән гореф-гадәтләр белән таныштырды. Яңа мәчет 1999 елда салына, аны төзү эшендә Зарифә һәм Галия Дулатовалар башлап йөри. Авылдагы иске мәчет бинасы да сакланып калган, аннан ерак түгел мәһабәт яңа мәчет балкый. Бүген дә мәчет эшен алып баручылар – хатын-кызлар. Алар исәп-хисап эшендә дә, кешене соңгы юлга озатуда, ашларын үткәрүдә дә ярдәм итәләр. Мәчет ябылып тормый, аз булса да җомгаларга йөрүче бар, хәтемнәр үткәрелгәндә кеше күп җыела, читкә китеп урнашкан авыл кешеләре дә даими ярдәм итеп тора. Борынгыдан калган кулъязма, басма мирасыбызга да биредә игътибар зур, алар кадерләп саклана. Мәсәлән, Супаева Мөнирә Мөхәммәдҗан кызы (1960 елгы) әби-бабалары Әбүбәкер кызы Хәнифә һәм Хөсәен улы Садыйктан калган китаплар белән таныштырды. Алар арасында «Рисаләи Тәүхид» (тулы, 1904), Коръән китабының җөзләргә бүлеп чыгарылган Санкт-Петербург басмасы (1900), «Фәүзәтен-нәҗаб» (тулы, 1904), «Кәлилә вә Димнә», «Кисекбаш» китабы (тулы, 1913), Шиһабетдин Рәхмәтуллин тәрҗемәсендәге «Каләф белән Турандык» (тулы, Казан, 1903), Габдулла Садыйкый-Җаекыйның «Бөек бер сәрвәт, яхуд Бик зур бер байлык» (роман, 1898) һ. б. китаплар бар.

Тархан авылында яшәүче Дулатова Рәхилә Әмрулла кызында (1967 елгы) «Мохтасарел-викая» (Казан, 1911), Хәләби тәрҗемәсе (тулы, 1891), Бохарзадә тәрҗемәсе (тулы, 1900), Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар» (тулы, Казан, 1900) китапларының басмалары саклана. Араларында кечкенә форматлы кулъязма китап та бар иде. Китапның сакланышы яхшы, күн тышлыкта, кара коңгырт кара белән язылган. Кустодлары бар. Кулъязманың ахыргы битенә күчерүченең исеме дә язылган: «Ошбу китап мин мулла Габделхәким бине Хөсәен углы Дулатовның торыр, әл-мәрхүм Исмәгыйль бине Арыслан». Шунысы да мөһим: Рәхилә ханымнар торган йорт – үзе үк зур тарихлы, истәлекле бина, ул бүген дә беренчел рәвешен саклап калган. Өйнең асты таштан, икенче каты агачтан эшләнгән. Беренче катта кибет тотканнар. Ләкин шаукымлы, афәтле елларда хуҗа сөргенгә озатылган, өе сатылган.

Темников шәһәреннән якынча 16 километр көньяк-көнчыгышка таба Енак авылы урнашкан. 1869 елдан ук билгеле бу авыл Краснослободск өязенә караган һәм 19 йортлы булып теркәлгән.

Енак авылында бүгенге көндә нибары 11 кеше гомер итә. Җәй көннәрендә яшәргә килүчеләр дә елдан-ел кими бара. Кайчандыр азан тавышлары яңгырап торган елларның хатирәсе булып, иске мәчет бинасы күренә, ул инде хәрабә хәлендә, аны агачлар күмеп бара. Берничә елдан биредә мәчетнең инде исән калган өлешләре дә юкка чыгар, урынын да искә алучы булмас кебек. Енак урамнары буйлап узганда, авыл үзе дә үле авыллар исемлегендә урын алмасмы дигән борчулы уйлар килә. Шунысы куанычлы: бетүгә йөз тоткан шушы авылда без бәһасез кульязмалар табу бәхетенә ирештек. Кыйммәтле табышларыбызның берсе – Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының күчермәсе. Кульязманың, кызганычка каршы, бер өлеше генә сакланып калган. Язу карасы коңгырт төстә, матур почерк белән башкарылган, кустодлары да бар. Пагинация карандаш белән сугылган, ләкин хаталы – кайбер битләрендә бөтенләй юк, мөгаен, алар соңыннан куелганнардыр. Полярларда кайбер урыннарда төзәтмәләр дә бар: поэманың төшеп калган юллары күчерүче тарафыннан дөресләп кертелгән. Кульязманың бер битендә «1836 года» дигән дата тора, күчерүче турында мәгълүмат табылмады.



Китаплар арасында тагын гарәпчә кульязма китап бар. Ул Мәмлиева Әйшәападан калган. Кульязманың тышлыгы күннән, сакланышы әйбәт, баш һәм ахыргы битләре генә югалган. Су билгеләре битләрдә күренми. Кустодлары бар, пагинация юк. Текст кара кара белән, кайбер сүзләр, билгеләр, шулай ук бүлек атамалары кызыл кара белән язылган. Китап тулаем гарәп телендә, фикъһ мәсьәләләренә багышлана, берничә биттә генә татар телендә илаһи мөнәҗәт һәм дини өйрәтмәләр урын алган. Бер битенә: «Краснос. у. д. Акашево. Муся Хөсяеновъ Агеевъ» дип язылган мөһер сугылган. Кульязма XIX гасырның икенче яртысына карый.



Енак авылында табып алынган тагын бер кулъязма – гарәп теле грамматикасы. Китапның тышлыгы, баш-ахыргы битләре булмаса да, калган өлешенең сакланышы әйбәт. Текст – коңгырт кара белән, бүлек башлары кызыл кара белән язылган. Битнең өске сул як өлешенә пагинация сугылган: сакланып калган соңгы биттә 1038 саны тора. Әлеге кулъязмалар Мирасханә фондларында урын алачак.

Бу якларга археографик сәфәрләр булган, билгеле. Мәмлиев Афзал ага үзләрендә сакланган күп кенә истәлекләрне шул вакытларда ук биреп җибәргән. Алар турында мәгълүмат Р.В. Абянов, М.А. Сәфәровлар чыгарган рәсемле «Темников: крепость империй» китабына да кертелгән [1: 71]. Әйтеп үтелгәнчә, Енак авылы – юкка чыгу алдында торган авылларның берсе. Күп кулъязмалар авылдагы ташландык, хәрабә хәлендәге өйләрдән табып алынды: шул рәвешле кадерле мирасыбызның бер өлешен юкка чыгудан коткарып калу бәхетенә ирештек. Мондый фәнни сәфәрләрнең оештырылуы исә тагын бер кат аларның никадәр әһәмиятле булуын раслап тора.

Тагын бер кечкенә һәм бетеп бара торган авылларның берсе – Татар Акашы (Акаш). Әлеге торак пункт йомышлы татарлар Акашевларның биләмәсе булган, атамасы да шуннан килеп чыккан.

Татар Акашы авылында бүгенге көндә 9 кеше генә көн күрә. Шулай булса да, авыл уртасында өр-яңа, бөтен уңайлыклары: суы, газы, тәһарәт бүлмәсе булган мәчет төзелгән. Ул Алия Кузовкинаның шәхси башлангычы һәм, әлбәттә, авыл кешеләре ярдәме белән күтәрелгән. Хәтемнәр үткәрү өчен биредә бөтен шартлар тудырылган, тирә-ягында да тәртип. Нигезләре беткән, якыннарын зиярәт итәргә кайткан һәрбер кеше өчен бу мәчет сыену урыны булып та тора.

Дашка – Темников районында кечкенә татар авылы, ул Вызна елгасы буенда урнашкан. Дашка авылы мәчетендә имамлык вазифаларын үтәгән Дашкин Мөнир Ибраһим улы белән очрашып, ул безне мәчет тарихы белән таныштырды, иске мәчет хакында да белгәннәрен сөйләде, балачак хатирәләрен яңартты. Язма чыганакларда Дашка авылы беренче тапкыр 1614 елны искә алына. 1866 елда 7 хуҗалык була. Төп халкы – морза Дашкиннар нәселеннән. Биредә яшәүчеләр белән авылның бай тарихын да искә төшердек. Тирә-якны кирпеч белән тәэмин итеп торган кирпеч заводы, аның хуҗалары хакында да авыл халкы мәгълүматлы, ул елларның җанлы истәлеге булган бай йорты, заводның сакланып калган бер өлеше дә тарихыбызны онытмаска, хәтердән җуймаска ярдәм итеп тора.

Дашкина Мөнирә Ибраһим кызы (1957 елгы) Нурхәят Сабит кызыннан калган китапларны саклый. Алар арасында борынгы Коръән китабы игътибарны җәлеп итте. Китап зәңгәрсу кәгазьгә басылган, су билгеләре дә бар (кояш эчендә монограммалар: АМ, контрамарка: «1» саны). Сирәк басмаларның берсе саналган бу Коръән XIX гасырның беренче яртысына карый. Шулай ук 1882 елгы «Ахырзаман ки-

табы», сакланышы уртача булган кульязма китап белән дә таныштык. Ядкәр тексты коңгырт кара белән язылган, пагинациясе юк. Кульязма битләрендә аерылышу-талак эшләре үрнәкләре, Мөхәммәд Пиргули китабына нигезләнеп, шәригать кануннары, мөселман дини йолаларын башкару тәртипләре язылган.

28 май көнне Татар Адае авылында эшләдек. Әлеге авыл Дашка һәм Шурбино авыллары белән бергә Аксел авыл советына карый. Авыл атамасы Адай морза Малишев исеменнән чыккан [4: 225].

Авыл зур түгел, бүгенге көндә 23 хуҗалык бар. Авылда имам булып торучы Акчурин Шамил Измаил улы безне мәчет тарихы белән таныштырды. Ялышевлар гаиләсе – Шамил Хәлил улы, Алия Фәттах кызы исә тел галиме өчен дә, фольклорчы, музыка белгече өчен дә зур табыш булды: гармунчы Шамил абыйдан (бүгенге көндә сукыр) бик күп җырлар язып алдык. Алар арасында туй йолалары, килен төшерү, кода-кодагыйларны каршы алу белән бәйле җырлар да бар. Кызганычка каршы, инде бүген онытыла барган йола-гадәтләр, кара-каршы әйтешү-җырулар халкыбызның никадәр бердәм, талантлы, моңлы, зиһенле булуы хакында да сөйли. Алия апа күрсәткән әбиләреннән калган камзул, калфак – татар кызларының нәзакәтлелеге, шул ук вакытта кул эшенә оста булуларының да бер күрсәткече. Адай авылына керү белән Акбулатовлар йорты исә үзенең матурлыгы, милли бизәкләр кулланып, күз явын алырлык итеп эшләнүе белән истә калды. Әлеге йортның проекты да – йорт хуҗасы Сафиулла Алим улыныкы. Әлеге нәсел арбачылар буларак танылган, авылда гына түгел, күрше авылларда да Сафиулла абыйның эшләре бар, йорт күтәрүдә дә ярдәм иткән ул. Акбулатовларның өй эчен нәсел шәҗәрәсе бизи. Күп тармаклы әлеге шәҗәрә Акбулатовларның үз нәселенә никадәр игътибарлы булуларын, нәсел тарихларын онытмауларын, тарихыбызга да мөнәсәбәтләрен күрсәтеп тора.

Мордовиянең Темников районындагы Карай (сөйләм телендә Плишкино) авылына XVI гасырда Россия дәүләтенең көньяк-көнчыгышындагы Темников чик сызыгында хезмәт иткән татарлар нигез салган. Авыл төзек, караулы булуы белән куандырды, мәчетләре эшләп тора. Имам Сәйфетдинов Рафик Фәрит улы – үзе дә белемле, тарихка битараф булмаган кеше. Авыл кешеләре сөйләве буенча да, биредә хәтемнәр еш үтә, дини бәйрәмнәребез онытылмый. Шулай ук яшь буынга дини тәрбия бирү, телебезгә хөрмәт тәрбияләү, аны саклау юнәлешендә дә эш алып барыла, борынгы мирасыбызны барлауга да игътибар зур. Мәчеттә аларны саклау өчен махсус урын каралган. Араларында басма китаплар, дәфтәрләр, аерым битләрдә язулар, догалыклар, мөнәҗәтләр дәфтәре һ. б. бар. Шунысы игътибарга лаек: китап күчерү традициясе бу якларда XX гасырның 70 нче елларына кадәр дәвам иткән. Шуның бер үрнәген без Карай авылында очраттык: «Ошбу «Мөһиммәтел-мөслимин» китабы язылды бер мең дә тукыз йөздә алтмышынчы елда. Укысыннар, укып, язгучыга хәердога кылсыннар. Борһанов Гыйрфанетдин». «Мондый күчермәләр

табылу татар халкының кульязма китап тардициясенең бик тирәннән килүенә һәм яшәүчәнлегенә дәлил» [7: 20].

Теви, Сухой авылларында татарлар һәм мукшылар бергәләшеп, бердәм булып гомер иткән, алар да өйрәнү өчен бик кызыклы булды. Теви (русча Татарское Тювеево) – Мордовиянең Темников районына кергән татар авылы. Авыл атамасы йомышлы татарлар, җир биләмәләре хуҗалары Тювеевлар фамилиясенә барып тоташа.

Теви авылында борынгы мәчет бинасының сакланып калып яңартылуы, матур гына эшләп килүе турында ишетү күңелгә рәхәтлек бирде. Имам Сәйфетдинов Рафик Утешев Әмир Изәтулла улыннан калган китапларны күрсәтте. Алар арасында Коръән китабы (1893), «Тәрҗемәи Дәкаикел-әхбар» (тулы түгел), «Кыйссасел-әнбия», «Нәсыйхатес-салихин» (тулы түгел) китаплары бар. Һ. Максудиның «Гыйбадәте исламия» китабының (1905) беренче битенә гарәп язуы белән: «Шушы китап иясе Нәгыймә бинте мулла Гыйззәтулла Чепаев китабы» диелгән. Г. Чепаев бу якларда указлы имам булып торган. Мәчет төзелешенә мөнәсәбәтле архив документларыннан алынган гаризаларда аның фамилиясе дә очрый.

Китаплар арасында кульязма җыентыкның булуы аеруча сөендерде. Аның тышлыгы, баш һәм ахыргы битләре юк. Сакланышы уртача, ахыргы битләре янып зыян күргән. Кустодлар бар, пагинация куелмаган. Күчерүченең исеме мәгълүм түгел. Биредә төрле эчтәлекле язмалар урын алган: төрле авыруларга дәвалар, Коръәннән аятьләр, әдәп-әхлак кагыйдәләре, Коръән сүрәләре, аятьләре белән өшкерү текстлары, тәртибе язылган.

Мордовиянең Темников районындагы татар авылы Яңгураз Олы Аксел елгасы буенда урнашкан. Авылга йомышлы татарлардан Янгуразовлар нигез салган, атамасы шуннан алынган диләр.

Яңгураз авылында бүгенге көндә 5 өйдә 9 кеше яши. Мәчетләре яңа, ул иске мәчет нигезендә яңартып ясалган. Авылда нигезләре беткән кешеләргә кайтып йөрү мөмкин булсын өчен, Равил һәм Рафаэль Богдашкиннарның зур тырышлыгы белән кунак йорты төзелгән. Янәшәдә музей бүлмәсе дә бар. Болар һәммәсе бер комплекс хасил итәләр. Шушы тырышлык, игелекле хезмәт артында өмет тә ята – авыл әле күтәрелеп, үсеп китәр, дип ышана алар. Мәчеттә борынгы китапларны җыеп, саклап торалар. Кызганычка каршы, мәчет җылытылмый, китаплар да дымнан зыян күрә. Күп ядкәрләр Янгуразов Каюм мулладан калган: Коръән, Һәфтияк, «Шәригать һәм заман» (1904, Ленинград), «Рисаләи Газизә» (1900, Петербург), Н. Думавиның «Хәсрәт бакчасы» китабы (1914, Казан), шулай ук XIX гасырның икенче яртысына караган татар телендә дини-әхлакый темаларга багышланган берничә кульязма дәфтәр (күчерүчесе мәгълүм түгел) һ. б. китаплар бар. Билгеле булганча, 1924 елда Мәскәүдә СССР халыкларының Үзәк нәшрияты тарафыннан Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» әсәре дөнья күрә. Яңгураз авылында шушы

басманы табу бәхетенә ирештек. Ул Язма мирас үзәгенә бүләк итеп бирелде.

Кулъязма китап-җыентыклар турында да аерым әйтеп үтәргә кирәк. Алар инде тулы булмаса да, тышлыклары сакланган, катыргы һәм күннән эшләнгән тышлыкка төпләнгәннәр. Төп текст кара кара белән, әһәмиятле саналган фразалар, бүлек башлары кызыл кара белән язылган. Кайбер битләрдә кустодлар булса да, җыйма китап итеп төпләнгәч, алар бөтен битләрдә дә юк. Китаплар, нигездә, XIX гасырның икенче яртысына карый, даталар юк. Бер китапның күчерүчесе дә мәгълүм булды: 3 биттә «Хисаметдин бине Гали бине Ибраһим» дип, имзасы куелган. Бу җыентыкларда дини темаларга багышланган сәхифәләр, хикәятләр китерелә, шигъри тезмәләр урын ала. Әлеге китаплар да Мирасханәгә тапшырылды.

Күрсәтелгән торак пунктларда яшәүче татарлар – көнбатыш диалектның темников сөйләше вәкилләре. Ул мишәр диалекты сөйләшләре арасында чылаштыручы төркемгә керә. Экспедиция барышында әлеге сөйләшләрнең үзенчәлекләре өйрәнелде, сөйләм үрнәкләре яздырып алынды.

Мордовия Республикасының Темников районында яшәүче татарларда халык авыз иҗаты ядкәрләре дә күп сакланган. Сан ягыннан караганда, иң киң таралган авыз иҗаты жанрларыннан җырларны аерып чыгарырга була, күбесе – кыска җырлар һәм такмаклар. Алар арасында лирик озын, йола һәм уен-бию җырлары да бар. Мәсәлән, Акаш авылында Янбухтин Равил Мифтах улы (1941 елгы), Янбухтина Разия Хәсән кызы (1937 елгы), Адай авылында Ялышев Шамил Хәлим улы (1958 елгы), Карай авылында Кичемасова Галия Мөхәммәтҗан кызы (1957 елгы), Чекашева Сания Нәбиулла кызы (1960 елгы), Позднякова Сания Шакир кызы (1953 елгы) безгә махсус берничә дистә халык җырын җырлап күрсәтте. Шулай ук Темников районында яшәүче милләттәшләребездән бәетләр, мөнәҗәтләр, халык уеннары, мифологик хикәятләр һәм халкыбызның традицион мәдәниятенә караган материаллар язып алынды.

Шулай итеп, 2025 елда без Мордовия Республикасының Темников районында нәтиҗәле эш алып бардык. Һәр белгеч кызыклы, зур мәгълүмат туплады бу төбәктә. Милләттәшләребез белән очрашып сөйләштек һәм аларның телен, сөйләм үзенчәлекләрен язып алдык. Диалектологлар бу якларда 1950–1970 елларда зур тикшеренүләр алып барган булса, без сөйләм үзенчәлекләрен заманча җиһазлар ярдәмендә теркәдек. Бу – татар диалектларының бүгенге торышын өйрәнү өчен бай фактик материал тупларга мөмкинлек бирде. Мордовиядә яшәүче татарларда көнбатыш диалектның чылаштыручы идиомнарга кергән темников сөйләшләре үрнәкләре, диалекталь сүзләрнең әйтелеш үзенчәлекләре дә аерым теркәп барылды.

Алга таба җирле халыкның сөйләм үзенчәлекләре, халык хәтерендә сакланган халык авыз иҗаты үрнәкләре, йола фольклоры тирәнтен өйрәнелеп, фәнни әйләнешкә кертеләчәк.

Экспедиция кыйммәтле кулъязма һәм басма китапларны табып, аларны юкка чыгудан саклап кала алды, күп ядкәрләрнең фотокүчермәләре алынды. Алар алга таба әле тагы да җентекләбрәк өйрәнеләчәк, аерым басмаларда урын алачак. Шулай ук татар халкының матурлыкка омтылышы, эстетик зәвыгы, хыялы да чагылган, шушы төбәк өчен генә хас булган орнаментлар белән бизәлгән шактый гына кул эшләре: чигүле сөлгеләр, тукылган өстәл япмалары, яулыклар; орчык, гөбе, бәләк кебек күп кенә агач эшләнмәләр шул төбәктәге музейларга тапшырылды. Шушы экспонатлар нигезендә музейларның «татар почмагы» да тулыландырылды, баетылды, сирәк ядкәрләр исә эзсез югалудан саклап калынды. Безгә чын күңелдән ярдәм иткән барлык кешеләргә – эшне оештырган җитәкчеләргә, юл күрсәтүчеләргә, авыл халкына олуг рәхмәтебезне җиткерәбез. Бүген дә алар белән элемтә өзелми, хезмәттәшлек дәвам итә.

## Әдәбият

1. *Абянов Р.В., Сафаров М.А.* Темников: крепость империй. М.: Изд. дом «Читай», 2022. 300 с.

2. Атлас татарских народных говоров Среднего Поволжья и Приуралья / науч. ред: Н.Б. Бурганова, Л.Т. Махмутова; сост: Н.Б. Бурганова, Л.Т. Махмутова (I т.), Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыкова, Т.Х. Хайрутдинова (2 т.). Казань, 1989. Прил.: Комментарии к Атласу. Казань, 1989. 300 с.

3. Атлас татарских народных говоров. URL: https://atlas.antat.ru/ (дата обращения: 02.02.2026).

4. *Әхмәтҗанов М.И.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 270 б.

5. *Борһанова Н.Б.* Татар теленең Мордва АССР территориясендә таралган сөйләшләре турында // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. Казань, 1962. С. 93–124.

6. *Гарипова, Л.Ш., Булатова Ә.К.* Мордовия Республикасы татар авылларына фәнни сәфәр нәтиҗәләреннән // Фәнни Татарстан. 2024. № 4 (44). Б. 143–152.

7. *Зайнеева Г.Н.* По итогам научной экспедиции в Пензенскую область // Актуальные проблемы регионоведения и науковедения: Сб. материалов XIV Респ. науч.-практ. конф. Казань, 2025. С. 161–167.

8. *Инжеватов И.К.* Топонимический словарь Мордовской АССР. Саранск: Мордов. кн. изд-во 1987.

9. Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации: справочник / отв. ред. Л.М. Айнутдинова, Б.Л. Хамидуллин. Казань: Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, 2016. 336 с.

10. Списки населенных мест Российской империи, составленные и издаваемые Центральным статистическим комитетом Министерства внутренних дел. Пензенская губерния: по сведениям 1864 года / обработан вычислителем А. Добровольским. СПб.: в тип. Карла Вульфа, 1861–1885, 1869. [3], XXXV, 119 с., [1] цв. карт. URL: https://upload.wikimedia.org/wikipedia/commons/8/83/Списки_населенных_мест_Российской_империи._Том_30._Пензенская_губерния.pdf (дата обращения: 22.02.2026).

11. *Фәйзуллина Ф.Г.* Пенза өлкәсендәге археграфик табышлар турында // Фәнни Татарстан. 2024. № 3. Б. 138–145.

***Гарипова Ләйлә Шамил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Булатова Әлфия Кәрим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Ямалтдинов Ильмир Илдар улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Гарипова Лейля Шамиловна,***
*кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник Центра письменного наследия Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*leilyashamilevna@mail.ru*

***Булатова Альфия Каримовна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела ареальной лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*alf_0082.82@mail.ru*

***Ямалтдинов Ильмир Ильдарович,***
*кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*jailmir@mail.ru*